Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы

КАРАР

«23» ноябрь 2021 ел № 55

Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре «Көньяк-Көнбатыш» микрорайоны территориясендә яшәүчеләр өчен үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 11 декабрендә 10 сәгать 00 минутта Нурлат шәһәре, Могыйнов ур., 10нчы йорт адресы буенча «Грани» мәдәни-ял үзәге бинасына төп керү юлы янында, «Көньяк - Көнбатыш» микрорайоны территориясендә (аңа Сембер (йортларның так номерлары), Юданов, Әхмәтов, Андреев, Кыямов, Виссарионов, Тихая, Чишмәле, Новостройки, Братская, Рябиновая, Имәнлек, Ипподромная урамнарында урнашкан барлык шәхси торак йортлар керә) яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены уздыруны билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә, аңа сайлау хокукына ия территориядә яшәүчеләрнең исемлекләрен, гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләүне, халыкка массакүләм мәгълүмат чараларында хәбәр итүне һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итүне йөкләп, гражданнар җыенын уздыру өчен бина бирергә һәм гражданнар җыенын уздыру датасына кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча, җыенга чыгарылучы сораулар буенча кирәкле һәм махсус белешмәләр булган оешмалар вәкилләренең җыенда булуын тәэмин итәргә, беркетмәне рәсмиләштерүне йөкләргә.

3. Гражданнар җыенында чыгарыла торган сорауны расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Нурлат шәһәрендәге « Көньяк - Көнбатыш » микрорайоны территориясендә Сембер (йортларның так номерлары), Юданов, Әхмәтов, Андреев, Кыямов, Виссарионов, Тихая, Чишмәле, Новостройки, Братская, Рябиновая, Имәнлек, Ипподромная урамнарында урнашкан барлык шәхси торак йортлар йортларында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1 000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә риза булырсызмы?

Татарстан Республикасы Нурлат шәһәрендә « Көньяк - Көнбатыш » микрорайоны территориясендә Сембер (йортларның так номерлары), Юданов, Әхмәтов, Андреев, Кыямов, Виссарионов, Тихая, Чишмәле, Новостройки, Братская, Рябиновая, Имәнлек, Ипподромная урамнарында юынтык суларны агызу челтәрләрен төзүгә әзерләнә торган проект-смета документациясен һәм дәүләт экспертизасын уздыруга әзерләнүче документларны хәзерләү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Нурлат шәһәре Советы Рәисе А.С. Әхмәтшин